Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге составына керүче Түбән Чаллы торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 9 ноябре № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Түбән Чаллы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак авыл җирлеге Түбән Чаллы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны Түбән Чаллы авылында зиратны төзекләндерүгә, Вахитов һәм Кызыл Армия урамнары арасындагы күперне төзекләндерүгә юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Кызыл Чапчак авыл җирлеге башлыгы Б.В.Ильдарханов